**«РАСЛЫЙМ»**
**Татарстан Республикасы**
**мәгариф һәм фән министры**
**_____________ И.Г.Һадиуллин**
**«19» ноябрь 2025 нче ел**

# Туган телдә белем бирү мәктәпләре укучылары өчен 2026 нчы елда туган (татар) әдәбияттан дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыру материалларының күрсәтмә варианты

# Демонстрационный вариант контрольных измерительных материалов для проведения государственной итоговой аттестации по образовательным программам основного общего образования 2026 года по родной (татарской) литературе для учащихся школ с родным языком обучения

разработан федеральным государственным автономным образовательным учреждением
высшего профессионального образования
«КАЗАНСКИЙ (ПРИВОЛЖСКИЙ) ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ»

подготовлен государственным бюджетным учреждением
«РЕСПУБЛИКАНСКИЙ ЦЕНТР МОНИТОРИНГА КАЧЕСТВА ОБРАЗОВАНИЯ»

утвержден МИНИСТЕРСТВОМ ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## Күрсәтмә вариантка аңлатма

2026 нчы елгы дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыру өчен контроль-бәяләү материалларының күрсәтмә варианты 9 нчы сыйныфта имтиханга әзерләнүчеләргә йөз тотып төзелде. Шуны истә тотарга кирәк: әлеге вариант имтиханда тәкъдим ителәчәк биремнәрне тулысынча чагылдырмый. Аның төп максаты – укучыларга сайлап алу имтиханына мөстәкыйль әзерләнергә юнәлеш бирү.

Күрсәтмә вариант укучыларда контроль бәяләү материалларының структурасы, биремнәрнең күләме, формасы, катлаулылык дәрәҗәсе (җиңел, уртача, авыр) турында гомуми күзаллау булдыруны күздә тота. Киңәйтелгән җавапларны бәяләү критерийлары укучыларда һәм гомумән киң җәмәгатьчелектә бу сорауларга куелган таләпләр турында күзаллау булдыра, әзерлек процессында игътибар ителәсе мәсьәләләрне ассызыклый.

Әлеге мәгълүматлар барысы да укучыларга татар әдәбиятыннан сайлап алу имтиханына әзерләнү юлын формалаштырырга, камилләштерергә ярдәм итәр.

## Биремнәрне башкару өчен күрсәтмә

Татар әдәбиятыннан дәүләт йомгаклау аттестациясе 2 бүлектән гыйбарәт.

Беренче бүлек тәкъдим ителгән әдәби текстларга эчтәлек һәм форма ягыннан бәя бирүне күздә тота. Текстларны башта игътибар белән уку, бары шуннан соң гына әсәргә яки тәкъдим ителгән өзеккә карата куелган сорауларга җавап бирә башлау мөһим. Беренче бүлектә ике вариант тәкъдим ителә. Укучы үз теләге белән шуларның БЕРСЕН генә сайлап алып эшләргә тиеш. Эпик яки драма әсәренә анализны эченә алган беренче вариантта киңәйтелгән җавап таләп иткән 3 сорау тәкъдим ителә.

Лирик әсәргә анализны эченә алган икенче вариантта киңәйтелгән җавап таләп иткән 3 сорау бирелә.

Беренче бүлектәге беренче һәм икенче вариантлардагы 1.1.1., 1.1.2. һәм 1.2.1., 1.2.2. биремнәренә җавап язганда темадан читкә китмичә, җавапны артык киңәйтмичә, 3-5 җөмлә күләмендә формалаштыру мөһим. Әмма бу сан якынча, шартлы, җавапны тикшерү барышында аның эчтәлегенә игътибар ителә. Өченче бирем исә (1.1.3. һәм 1.2.3.) чагыштырма планда җавап язуны таләп итә һәм аны 5-8 җөмлә күләмендә формалаштыру сорала.

Икенче бүлек дүрт сочинение темасын үз эченә ала. Алар аерым әсәрләргә мөнәсәбәтле кечкенә күләмле сочинение язуны күздә тота. Җавап бирү барышында шуның БЕРСЕНӘ генә сочинение форматында 200 сүздән дә ким булмаган сочинение язу сорала, 150 сүздән дә ким булган язмалар 0 балл белән бәяләнә.

Биремнәрне башкару өчен 210 минут вакыт каралган. Эшнең беренче бүлеген башкару өчен – 2 сәгать, икенче бүлекне үтәүгә калган вакыт күздә тотыла.

**Уңышлар телибез!**

# 1 БҮЛЕК

**1 бүлектәге ике вариантта тәкъдим ителгән өзекләрне укыгыз һәм шул вариантларның БЕРСЕНДӘ каралган биремнәргә генә җаваплар языгыз.**

## Вариант 1

**Тәкъдим ителгән өзекне укыгыз һәм 1.1.1 – 1.1.3 биремнәренә җавап бирегез.**

...Самолет ераклашты. Лейтенант команда бирде булса кирәк, алда яткан кызылармеецлар ашыгып тора башладылар. Зариф та урыныннан кузгалды. Ләкин ул бер адым да атларга өлгермәде, үзеннән биш-алты метр гына читтә өч-дүрт яшьлек кыз баланың басып торганын күреп, ихтыярсыз тукталды. Баланың берәр якын кешесен күрергә теләп, тирә-ягына каранды, ләкин якында һичкем барлыгы сизелми иде. Зариф бик гаҗәпләнеп янә балага карады; бала чыннан да ялгыз иде. Ул үзе биеклек кенә бер куак янына баскан, кечкенә кулына берничә бөртек каен җиләге учлаган, шуны кабарга хәзерләнгән җиреннән туктап, зур соры күзләре белән Зарифка исе китеп карап тора. Озак елаудан аның күз төпләре шешенгән, түгәрәк битендә яшь юллары калган... Ләкин хәзер тынычланган, нинди хәлдә булуын оныткан, ахрысы – аяк астындагы җиләкләрне җыярга керешкән. Аның өстендә зәңгәр сукнодан җәйге пальто, башында фетрдан тегелгән кара шапочка, аны кызыл тасма белән ияк астыннан китереп бәйләгән; аякларында озын сары оеклар белән сары ботинкалар һәм бер аягында галошы бар, икенчесен төшереп калдырган, ахрысы.

Зариф бу баланың дошман явыннан качып баручылардан югалып торып калганын бик тиз төшенә, һәм аңарда кузгалган беренче теләк – баланы тизрәк күтәреп аласы килү булды. Шул ук вакытта ул ротадан аерылып калырга һич ярамаганлыгын да уйлап алды. Беренче хәрәкәте аның ротасы артыннан китү өчен юлга таба борылу булды. Ләкин ул, бер адым да атламастан, кинәт балага таба кире борылды, ашыгып аның янына барды да җитез генә күтәреп алды.

Бала куркуыннан:

– Әни! – дип кычкырып җибәрде һәм, җиләген йомарлаган кулы белән Зарифның битеннән этәреп, аякларын селкеп еларга кереште.

Зариф, баланы кысып тоткан килеш, аяк астында аунаган чыбыкларга, агач төпләренә абынмас өчен сикерә-атлый, ашыгып юлга чыкты. Шундый кыска вакыт үтүгә карамастан, рота шактый ераклашкан иде инде. Зариф, сыңар кулы белән иңендәге мылтыгын уңайлый төшеп, кызу-кызу атлый башлады.

Бала елап арыган, күрәсең; тиз арада аның елавы тавышсыз үксүгә әйләнде. Зариф кесәсеннән бер шикәр кисәге чыгарып, тузанын өргәләп, балага тоттырды. Бала башта башын селкегән булды, аннары шикләнеп кенә буш кулы белән шикәрне алды һәм йомарлап күкрәгенә кысты.

Зариф йомшак тавыш белән:

– Аша, аша! – диде һәм баланың аркасыннан сыйпап, сөеп куйды. Балага шул җитә калды: ул үксүеннән туктады, тынычланган кебек булды һәм, Зарифның кулында акрын гына селкенеп, тирә-ягына каранып бара башлады. Зариф баланың юка киеме аша йомшак тәнен, җылысын, тәмле исен тоя иде. Ниндидер бер ләззәтле сагыну белән шул йомшак тәнне, шул тәмле бала исен тагы да ныграк тоярга, ничектер үзенә сеңдерергә теләгәндәй, ул баланы акрын гына кыса, аркасыннан сыйпый... Һәм аның йөрәге төбеннән әйтеп биреп булмый торган сөенечле бер ярату хисе җылы дулкын булып күтәрелә бара иде. Зарифның да бит өч яшьлек Фәридәсе бар. Зариф та бит эти, һәм, бәлки, шушы минутта ул үз баласы белән бу бала арасында аерма тоймыйдыр, киресенчә, бу балага биргән мәхәббәтен һәм назын үз Фәридәсенә биргән кебек тоядыр. Ул, баланың йомарлаган кулын тотып, кипкән иреннәренә тидереп алды. Акрын, назлы гына:

– Әтиең, әниең бармы? – дип сорады, һәм аның тамак төбе кытыкланып, күзләре дымланып китте.

Бала ачык тавыш белән җавап кайтарды:

– Әнием дә бар, әтием дә бар... безнең әле тагын кәҗәбез дә бар. Бәтиләре ап-ак.

Зариф елмаеп, балага күтәрелеп карады:

– Шулаймыни? Кара син, ап-аклар икән... Ә әтиең кайда соң?

– Китте.

– Кая китте?

– Белмисеңмени? Фронтка, – диде бала һәм аз гына тынып торганнан соң исенә төшкәндәй, – ул лейтенант, – дип куйды...

*Ә.Еники «Бала»*

**1.1.1 һәм 1.1.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.1.** Әлеге өзектә балага хас нинди сыйфатлар ачыла?

**1.1.2.** Әлеге өзектә Зарифның балага булган мөнәсәбәтен, яратуын күрсәтү өчен автор нинди образлардан һәм алымнардан файдалана?

**1.1.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.3.** Ә.Еникинең «Бала» һәм «Кем җырлады?» хикәяләреннән алынган өзекләрдә авторның сугышка булган мөнәсәбәтен, бәясен чагыштырыгыз. Нинди охшаш һәм аермалы яклар күрәсез?

Ватан сугышының дәһшәтле көннәреннән берсе иде.

Көзге караңгы төндә кечкенә генә җимерек станциядә ике эшелон очрашып, янәшә туктадылар. Боларның берсе тылдан фронтка яңа хәрби часть алып баручы эшелон, икенчесе фронттан тылга яралылар төяп кайтучы санитар поезды иде. Эшелоннар икесе дә, бик озын булып, гел кызыл вагоннардан торалар. Тик санитар поездының гына паровозга якын очында бер-ике классный вагоны бар, ә калганнары исә кечкенә чуен мичләр куеп җылытылган теплушкалар иде.

Станция дигән нәрсәнең үзе дә, бер генә бер каралтысы да юк – бар да җимерелеп беткән. Тик юллар буенда берничә кат юан бүрәнәләр түшәп һәм балчык өеп эшләнгән зур гына землянка ялгызы калкып тора... Бөтен станциясендә ник бер генә тычкан уты җемелдәсен – әйләнә-юнь морҗа эчедәй кап-кара. Ләкин еракка күз ташласаң, сугыш барган якта, кайдадыр офык артында ук, күк чите буйлап сузылган кандай кызыл шәүлә тибрәнә. Янамы анда берәр зур авыл, туплар атышы шулай чагыламы – моннан карап белеп булырлык түгел.

Бөтен әйләнәдә фронтка якын җирләрдә генә була торган үле тынлык хөкем сөрә. Хәтта эшелоннар башындагы ике кап-кара паровоз да тып-тын тора, әйтерсең казаннарын сүндереп, аларны ташлап киткәннәр... Эшелоннарны томалап куйганнар диярсең, берсеннән-бер көлгән, сөйләшкән тавыш та ишетелми, төшеп-менеп йөрүче дә күренми. Тик араларыннан узганда, туктала биреп колак салсаң, бер яктагы кызыл вагоннардан ара-тирә каты хырылдау, икенче яктагы теплушкалардан авыр ыңгырашу ишетелеп кала. Берәүләр соңгы тапкыр йокы туйдыралар, икенчеләр бер күз йомарга гаҗиз булып яталар, күрәсең.

...Теплушкаларның берсендә түбәнге сәкедә каты яралы яшь лейтенант – татар егете ята. Егетнең хәле авыр, уң аягы аның тездән югары киселгән, ә санитар поезды юлга чыккач, аңарда гангрена башланды. Менә бер тәүлек инде ул, ни йоклый, ни уяна алмыйча, ярым һушын югалткан хәлдә ята. Вакыт-вакыт ул аңына килә, шул чакта авыр газаптан талган күзләрен ача, янында басып торган ак халатлы шәфкать туташын күрә, аның салкын кулын маңгаенда тоя. Бер мәлгә егет үзен җиңеләеп киткәндәй хис итә, хәтта уң аягы бар, ул кычыта кебек тоела аңа... Ләкин бу хәл озакка бармый, тагын бөтен тәне буйлап ут тарала, күзләрендә бизгәк чаткысы кабына. Бераздан егет күз кабакларын акрын гына йома һәм, һушын югалтып, яңадан эссе томан эчендә йөзә башлый. Яткан урынын да, туташның кагылуын да, хәтта шприцның очлы энәсен дә ул инде тоймый.

... Ә икенче көнне санитар поезды тагын бер җимерек разъездга җитеп туктады. Кызыл теплушкадан егетнең үле гәүдәсен носилкага салып чыгардылар да юлдан ерак түгел бер калкулык өстендәге ялгыз нарат төбенә илтеп күмделәр. Күмеп беткәч, туфрак өеменең башына кечкенә фанер кадакланган казык утыртып куйдылар. Фанерга кара буяу белән егетнең исеме, фамилиясе, туган һәм үлгән

еллары язылган иде. Күмүчеләр, башларыннан салып, кабер әйләнәсендә бераз тынып тордылар да аннан барысы берьюлы вагоннарына таралдылар.

Поезд китте, ялгыз кабер торып калды.

Кинәт җил исте, биек нарат, эре яңгыр тамчыларын җиргә коеп, салмак кына башын чайкады. Күктәге салынкы соры болытлар, кемгәдер юл ачкандай, икегә аерылдылар. Шунда ук зәңгәр ачыклыктан, бәхилләшергә соңга калгандай, ашыгып кояш карады. Нарат төбендәге кабер өсте, әйтерсең егетнең җирдә калган, үлмәгән һәм мәңге үлмәячәк якты хыяллары белән кинәт нурланып балкыды.

*Ә.Еники «Кем җырлады?»*

## Вариант 2

Ак чәчәкләр чыңлап тора,
Җырлап тора әйләнәдә.
Ак каеннар сылу-сылу
Яшь кызларга әйләнә дә,
Җыйнаулашып, тезелешеп
Төшеп китә Сөн буена.
Яп-ялангач калып кына
Су керергә төн буена.

Ә малайлар шундый монда:
Хикмәт кенә уйлап йөри,
Япь-яшь кенә яшеннәрне
Камчы итеп уйнап йөри.
Шул камчыны шаяртып бер
Шартлатсалар болгый-болгый,
Баш очында утлар уйный,
Күкләр күкри ургый-ургый...

Тайлар монда бер урында
Чыдый алмый биеп тора.
Ә басулар шундый биек –
Офыкка ук тиеп тора...
Менә шундый инде минем
Туган җирем, туган ягым.
Мин төзәлә алмам ахры –
Мактанылды менә тагын..

*Р.Миңнуллин «Шундый минем туган ягым»*

**1.2.1 һәм 1.2.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.1.** Туган ягына булган мөнәсәбәтен күрсәтү өчен шагыйрь нинди тел-сурәтләү чараларыннан файдалана?

**1.2.2.** Әлеге шигырьдә автор фикерен, идеяне билгеләгез һәм язып куегыз.

**1.2.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.3.** Р.Миңнуллинның «Шундый минем туган ягым» һәм Г.Тукайның «Туган авыл» шигырьләрендә лирик геройга бәя бирегез. Аларның бирелешендә нинди охшаш һәм аермалы яклар бар?

Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;
Аулыбызның ямен, суы тәмен беләм,
Шуңар күрә сөям җаным-тәнем белән.

Ходай шунда җан биргән, мин шунда туган,
Шунда әүвәл Коръән аятен укыган;
Шунда белдем рәсүлемез Мөхәммәдне,
Ничек михнәт, җәфа күргән, ничек торган.

Истән чыкмый монда минем күргәннәрем,
Шатлык белән уйнап гомер сөргәннәрем;
Абый белән бергәләшеп кара җирне
Сука белән ертып-ертып йөргәннәрем.

Бу дөньяда, бәлки, күп-күп эшләр күрем,
Билгесездер – кая ташлар бу тәкъдирем;
Кая барсам, кайда торсам, нишләсәм дә,
Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем.

*Г.Тукай «Туган авыл»*

# 2 БҮЛЕК

**2 бүлек биремнәренә сочинение язу барышында тәкъдим ителгән темаларның (2.1. – 2.4) бары БЕРСЕН генә сайлап алыгыз. Җаваплар бланкында үзегез сайлаган теманың номерын күрсәтегез. Үзегез сайлаган темага, әдәби материалга таянып, 200 сүз күләмендә киңәйтелгән җавап языгыз. Куелган проблемаларны, автор позициясен үзегез аңлаганча ачыклап, тулы җавап бирүегез сорала. Әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дәлилләгез. Иншаның төзелешен уйлагыз, эзлеклелекне саклагыз, анализ барышында теоретик төшенчәләргә таяныгыз. Сочинениенең күләме 150 сүздән дә ким булмаска тиеш, шуннан ким булган очракта инша 0 балл белән бәяләнә.**

**2.1.** Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә мәхәббәт темасы.

**2.2.** Гали Рәхимнең «Яз әкиятләре» хикәясендә күтәрелгән проблемалар.

**2.3**. Фатих Хөснинең «Йөзек кашы» повестенда Айдар һәм Госман образларына чагыштырма бәя бирегез.

**2.4**. Хәсән Туфан иҗатында лирик герой.

# КИҢӘЙТЕЛГӘН ҖАВАПЛАРНЫ ТАЛӘП ИТҮЧЕ БИРЕМНӘРНЕҢ ҮТӘЛЕШЕН ТИКШЕРҮ ҺӘМ БӘЯЛӘҮ КРИТЕРИЙЛАРЫ

## 1.1.1, 1.1.2. һәм 1.2.1., 1.2.2. биремнәрен (3-5 җөмлә күләмендә) бәяләү

3-5 җөмлә күләмендәге киңәйтелгән җавапны таләп итә торган бирем. Җавапка билгеләнгән күләм шартлы, ул сорауның катлаулылыгына һәм эчтәлегенә бәйле. Укучы сорауга эчтәлеге ягыннан тулы җавап язарга, әмма үз җавабын мөмкин булган кадәр кыска формалаштырырга тиеш.

| Критерий | Балл |
|---|---|
| **1. Фикер тирәнлеге һәм җавапның дәлилләнгән булуы** | |
| а) имтихан тапшыручы укучы биремнең үзенчәлегенә төшенгән: сорауны аңлап җавап биргән, автор позициясен ачкан, үз фикерен дәлилләгән, фактик хаталар юк | **2** |
| б) имтихан тапшыручы укучы сорауга җавап бирә, ләкин җавабын нигезләп бетерә алмый / яки җавабын әсәрнең кыскача эчтәлеген сөйләү белән генә чикли, җавап хаталы һәм төгәл түгел / яки җавапта бер-ике фактик хата күзәтелә | **1** |
| в) укучы сорауга бөтенләй җавап бирмәгән / яки эчтәлеге ягыннан сорауга туры килми торган җавапны язган / яки 3 һәм аннан да күбрәк фактик хата ясалган | **0** |
| **2. Җавапның сөйләм нормаларына туры килүе** | |
| а) Җавапта бер генә сөйләм хатасы бар | **1** |
| б) җавапта сөйләм хаталары бердән артык | **0** |
| **Иң югары балл** | **3** |

## Чагыштырма пландагы 1.1.3. һәм 1.2.3. биремнәрен бәяләү

5-8 җөмлә күләмендәге киңәйтелгән җавапны таләп итә торган бирем. Җавапка билгеләнгән күләм шартлы, ул сорауның катлаулылыгына һәм эчтәлегенә бәйле. Укучы сорауга эчтәлеге ягыннан тулы җавап язарга, әмма үз җавабын мөмкин булган кадәр кыска формалаштырырга тиеш.

| Критерий | |
|---|---|
| **1. Җавапның төгәллеге, тирәнлеге, дәлилләнгән булуы** | **Балл** |
| а) укучы сорауны аңлап, төгәл җавап бирә, авторлар позициясенә нигезләнеп, үз фикерен җиткерә ала, соралган төп үзенчәлекләрне билгели, мисаллар ярдәмендә ныгыта, анализлау сәләтен күрсәтә, җавабын дәлилли, фактик хаталары юк | **2** |
| б) укучы сорауны тулаем аңлап та, җавап бирү барышында гомуми җөмләләр белән чикләнә, мисаллар белән ныгытып, төгәл җавап бирми / сорауга җавап өстән-өстән генә, бик гади аңлатыла, әдәби-теоретик | **1** |

| | |
|---|---|
| төшенчәләр ярдәмендә ныгытылмый / яки 1-2 фактик хата күзәтелә | |
| в) укучы сораугa бөтенләй җавап бирми / яки эчтәлеге ягыннан сораугa туры килми торган җавапны яза / яки 4 тән артык фактик хата күзәтелә | **0** |
| **2. Җавапның, әдәби текстларны чагыштырып, нигезле, дәлилләнгән булуы** | **Балл** |
| а) җавап чагыштырма планда языла, мисаллар ярдәмендә ныгытыла, соралган әсәрләр (әсәрләр) җитәрлек күләмдә файдаланыла (өзекләр китерелә, кыскача эчтәлек сөйләнә, текстның микротемаларына мөрәҗәгать ителә, әсәрләргә сылтамалар бирелә һ.б.) | **2** |
| б) җавап бирү барышында әсәрләрне чагыштыру җитәрлек күләмдә түгел, мисаллар файдаланып та, җавапны дәлилли алмый, мисаллар нигезле түгел / яки текстның бу җавапны дәлилли торган өлешләре файдаланылмый | **1** |
| в) җавап бирү барышында әсәрләр чагыштырылмый / яки кирәкле аспектта чагыштырылмый | **0** |
| **3. Җавапның әдәби сөйләм нормаларына туры килүе** | **Балл** |
| а) 2-3 сөйләм хатасы күзәтелә | **1** |
| б) сөйләм хаталары 2дән артык | **0** |
| *Иң югары балл* | **5** |

## Сочинение биремен бәяләү

2 нче бүлекнең бирем җаваплары иң мөһимнәрдән санала, шулар арасында иң әһәмиятлесе булып беренчесе – эчтәлек ягы санала. Тикшерү барышында җавапның эчтәлеге 0 балл белән бәяләнгән очракта бирем эшләнмәгән булып санала һәм **алга таба тикшерелми**. Калган бәяләү аспектлары буенча 2 нче биремнәрнең җавапларын тикшерү бланкына 0 балл куела.

Җавапны бәяләгәндә, язылган иншаның күләме исәпкә алына. Имтихан бирүчеләргә 200 сүздән ким булмаган күләмдәге текстны язу тәкъдим ителә. Әгәр инша тексты 150 сүздән ким булса, мондый эш үтәлмәгән дип санала һәм “0” балл белән бәяләнә.

| **Критерий** | |
|---|---|
| **1. Җавапның төгәллеге, тирәнлеге, дәлилләнгән булуы** | **Балл** |
| а) укучы сорауны аңлап, төгәл җавап бирә, автор позициясенә нигезләнеп, үз фикерен җиткерә ала, соралган төп үзенчәлекләрне билгели, мисаллар ярдәмендә ныгыта, анализлау сәләтен күрсәтә, җавабын дәлилли, фактик хаталары юк | **3** |
| б) укучы сорауны тулаем аңлап та, җавап бирү барышында гомуми җөмләләр белән чикләнә, мисаллар белән ныгытып, төгәл җавап бирми / яки 1-2 фактик хата күзәтелә | **2** |
| в) сораугa җавап өстән-өстән генә, бик гади аңлатыла, әдәби-теоретик | |

| | |
|---|---|
| төшенчәләр ярдәмендә ныгытылмый / яки 3-4 фактик хата күзәтелә | **1** |
| г) укучы сорауга бөтенләй җавап бирми / яки эчтәлеге ягыннан сорауга туры килми торган җавапны яза / яки 4 тән артык фактик хата күзәтелә | **0** |
| **2. Әдәби-теоретик төшенчәләрне аңлау, алар белән эшләү дәрәҗәсе** | **Балл** |
| а) әсәрне анализлау яки чорга характеристика бирү барышында әдәби-теоретик төшенчәләр аңлап, урынлы кулланыла, җавап теоретик яктан югары дәрәҗәдә язылган | **2** |
| б) имтихан тапшыручы әдәби-теоретик төшенчәләрне аңлый, әмма әдәби материалга анализда аларны куллану барышында 1 төгәлсезлек күзәтелә | **1** |
| в) укучы әдәби-теоретик төшенчәләрне дөрес кулланмый яки әдәби-теоретик төшенчәләрдән мәгълүматлы түгел, әдәби материалга анализда аларны куллану барышында 1 дән артык хата ясый | **0** |
| **3. Җавапның, әдәби текстларны кулланып, нигезле, дәлилләнгән булуы** | **Балл** |
| а) җавап мисаллар ярдәмендә ныгытыла, соралган әсәр (әсәрләр) җитәрлек күләмдә файдаланыла (өзекләр китерелә, кыскача эчтәлек сөйләнә, текстның микротемаларына мөрәҗәгать ителә, әсәрләргә сылтамалар бирелә һ.б.) | **2** |
| б) җавапта әсәрнең (әсәрләрнең) турыдан-туры эчтәлеге генә урын ала / яки текстның бу җавапны дәлилли торган өлешләре файдаланылмый | **1** |
| в) җавап бирү барышында әсәр (әсәрләр) бөтенләй файдаланылмый, нигезләнми | **0** |
| **4. Җавапның эзлеклелеге, фикерне җиткерү мөмкинлеге** | **Балл** |
| а) җавап логик яктан эзлекле языла, фикерләр үзара бәйләнештә бирелә, төгәл җиткерелә | **2** |
| б) җавапның мәгънәви өлешләре үзара логик яктан эзлекле языла, әмма аерым кабатлаулар, төгәлсезлекләр күзәтелә / җавап эзлекле булып та, фикер еш кабатлана, төп темадан читкә киткән урыннар күзәтелә | **1** |
| в) җавап логик яктан эзлекле язылмаган, эзлеклелек тупас бозылган, җавапта гомуми мантыйк күренми | **0** |
| **5. Җавапның әдәби сөйләм нормаларына туры килүе** | **Балл** |
| а) сөйләм хаталары юк яки 1 сөйләм хатасы ясалган | **3** |
| б) 2-3 сөйләм хатасы күзәтелә | **2** |
| в) 4 сөйләм хатасы ясалган | **1** |
| г) сөйләм хаталары бик күп (5 яки аннан да артык) булып, фикерне аңлауда кыенлыклар тудыра | **0** |
| *Иң югары балл* | ***12*** |

**Имтихан эше өчен түбәндәге билгеләр куела:**

Имтиханда тест өлеше юк, барлык биремнәр дә киңәйтелгән җавап язуны таләп итә һәм экспертлар таарфыннан түбәндәге критерийлар буенча тикшерелә:

| К1 | К2 | К3 | К4 | К5 | К6 | К7 | К8 | К9 | К10 | К11 | К12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **1 бирем** | | **2 бирем** | | **3 бирем** | | | **Инша (сочинение)** | | | | |
| 2 | 1 | 2 | 1 | 2 | 2 | 1 | 3 | 2 | 2 | 2 | 3 |

Иң югары балл – 23 балл.

Имтихан эшләре ике эксперт тарафыннан тикшерелә, аларның бәяләрендәге баллар аермасы 3 һәм аннан да күбрәк балл булган очракта өченче эксперт билгеләнә.

**Балларны билгегә әйләндерү шкаласы**

| **Билге** | **«2»** | **«3»** | **«4»** | **«5»** |
|---|---|---|---|---|
| **Баллар** | **0-6** | **7-13** | **14-18** | **19-23** |